**СОВЕТ НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422630 с. Нармонка,
ул. Молодежная , д.12 а
тел: 4-62-24

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**
422630 Нармонка авылы,
Яшьләр урамы, 12 а нчы йорт,
тел: 4-62-24

---

**2025 елның «16» июне** **257 номер**

# КАРАР

## Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ЗРТ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советы муниципаль берәмлеге уставының 13 маддәсенең 3.3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Камская новь» газетасында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Нармонка
авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Ф. Мөбәрәкшин**